КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 сентябрь г.Казань № 1035

Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә аларның Татарстан Республикасы территориясендә туризм инфраструктурасын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Туризм үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 2439 номерлы карары белән расланган «Туризм үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасының 7 нче кушымтасында бирелгән Туризм инфраструктурасын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 21 июлендәге 522 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу减 карарга теркәлгән Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә аларның Татарстан Республикасы территориясендә туризм инфраструктурасын үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итү

максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 8 пунктындагы «з» пунктчасыннан, 27 пунктындагы өченче абзацыннан, Тәртипнең 5 нче кушымтасындагы 10 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин